РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«31» март 2023ел Олы Кайбыч ав. № 179

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тибын үзгәртү юлы белән төзелә торган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль казна учреждениеләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 13 апрелендәге 168 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2018 елның 27 декабрендәге 559-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тибын үзгәртү юлы белән төзелә торган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 13 апрелендәге 168 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 2.1 пунктындагы 3 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) администрациясе» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 3 нче кушымтаның 6 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатурага таләпләр

1. Кайбыч муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары вазыйфасына түбәндәге квалификация таләпләренә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары билгеләнә:

1) югары белеме булу;

2) дәүләт, муниципаль идарә, дәүләт, муниципаль контроль (аудит), икътисад, финанс, юриспруденция өлкәсендә кимендә биш ел эшләү тәҗрибәсе;

3) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, шул исәптән Россия Федерациясенең бюджет законнарын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларны, Россия Федерациясенең тиешле субъекты законнарын һәм башка норматив хокукый актларны, Кайбыч муниципаль районы Уставын һәм башка муниципаль хокукый актларны, шулай ук Россия Федерациясе Хисап палатасы раслаган Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль һәм эксперт-аналитик чараларын уздыру өчен тышкы муниципаль аудит (контроль) стандартларына карата гомуми таләпләрне белү.

1.1. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатураларның әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү үткәрү тәртибе 2011елның 07 феывралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 11 өлешендә каралган очракта, Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан билгеләнә.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар өчен Татарстан Республикасы Законы, район Советы карары белән белем һәм эш тәҗрибәсенә өстәмә таләпләр куелырга мөмкин.

3. Россия Федерациясе гражданы контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары яисә аудиторы вазыйфасына түбәндәге очракларда билгеләнә алмый:

1) аның бетерелмәгән яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булу;

2) аны закон көченә кергән суд карары белән хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип тану;

3) гәр граждан дәгъва кыла торган вазыйфасы буенча бурычларны үтәү мондый мәгълүматлардан файдалану белән бәйле булса, дәүләт серен тәшкил иткән һәм федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән белешмәләргә кертүне рәсмиләштерү процедурасын узудан баш тарту;

4) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату яисә чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) йә яшәү төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;

5) әлеге статьяның 4 пунктында каралган нигезләр булу.

4. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары вазыйфаларын биләүче гражданнар (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, абый-энеләр, апа-сеңелләр, шулай ук абыйлы-энеле, апа-сеңелләр, ата-аналар, ир белән хатынның балалары) район Советы рәисе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туган була алмыйлар.

5. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнә алмыйлар. Шул ук вакытта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит

дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый.

6. Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы затлар үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә белешмәләр тапшырырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А. И. Рәхмәтуллин